**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**10.04.2026 ел** **№ 20**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- 2014 елның 19 ноябрендәге 144.1 номерлы «Иске Маврин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәне раслау турында»;
- 2015 елның 01 сентябрендәге 178 номерлы «Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 144.1 нче номерлы «Иске Маврин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»;
- 2022 елның 31 маендагы 67 номерлы «Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 144.1 нче номерлы «Иске Маврин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»;

- 2023 елның 07 декабрендәге 120 номерлы «Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 144.1 нче номерлы «Иске Маврин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»;

- 2017 елның 26 октябрендәге 87 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар башкаручылар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында»;

- 2022 елның 31 маендагы 68 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар башкаручылар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 26 октябрендәге 87 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (www.pravo.tatarstan.ru), авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **Р.Г. Нургалеев**